**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 май 2014 ел Казан шәһәре № 3-3/э

***ААҖ "Азнакай җылылык челтәре предприятиясе" һәм ААҖ "Челтәр компаниясе" челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен үзара исәп-хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында***

"Электр энергетикасы турында" 26.03.2003 №35-ФЗ Федераль законы нигезендә, "Электроэнергетика өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) билгеләү" 29.12.2011 №1178 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, "Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә бәяләрне һәм җайга салынучы тарифларны исәпләү өчен методик күрсәтмәләрне билгеләү турында" 6.08.2004 г. № 20-э/2 Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең карары, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. Карарның гамәлгә керү көненнән алып 2014 елның 31 декаберенә кадәр ААҖ "Азнакай җылылык челтәре предприятиясе" һәм ААҖ "Челтәр компаниясе" челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен үзара исәп-хисап тоту индивидуаль тарифларны, календарь бүленеше нигезендә, әлеге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен үзара исәп-хисап тоту индивидуаль тарифларны билгеләү турында» 14.12.2012 № 3-12/э Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары 2-4 кушымталарның 46 пунктын үз көчен югалткан дип исәпләргә.

3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына кушымта
30 май2014 ел. № 3-3/э

Әлеге карарның гамәлгә керү көненнән 2014 елның 31 декаберенә кадәр ААҖ "Азнакай җылылык челтәре предприятиясе" һәм ААҖ "Челтәр компаниясе" челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен үзара исәп-хисап тоту индивидуаль тарифларын календарь бүленеше нигезендә билгеләү турында

(ӨБС исәпкә алынмый)

| № п/п | Челтәр оешмасы исеме | Карарның гамәлгә керү көненнән 2014 елның 30 июненә кадәр | | | 2014 елның 01 июленнән алып 2014 елның31 декаберенә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Икеставкалы тариф | | Одноставочный тариф | Икеставкалы тариф | | Берставкалы тариф |
| | | Электр челтәрен карап тоту ставкасы | технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | ставка за содержание электрических сетей | ставка на оплату технологического расхода (потерь) | |
| | | сум./кВт·ай | сум./кВт·сг | сум./кВт·сг | сум./кВт·ай | сум./кВт·сг | сум./кВт·сг |
| 1 | АҖ "Азнакай җылылык челтәре предприятиясе" һәм ААҖ "Челтәр компаниясе" | 41,29403 | 0,05262 | 0,16144 | 42,47341 | 0,06182 | 0,17375 |